**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Жуково авыл җирлегенең Кызыл Тархан торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**25 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлегенең Кызыл Тархан торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең Кызыл Тархан торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Кызыл Тархан авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;
- Кызыл Тархан авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзекләндерү;
- Кызыл Тархан авылында чишмәне төзекләндерү;
- Кызыл Тархан авылында һәлак булган сугышчылар истәлегенә обелиск төзү.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Н.П. Сапожников**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Жуково авыл җирлеге башлыгы** **Н.П. Сапожников**